# КАРАР

2022 елның 19 ноябре, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 14 ноябрендә, 2022 елның 18 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылы территориясендә теркәлгән , балигъ булган һәр яшәүчедән, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокльы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2023 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ятмас Дусай авылында вак таш җәеп, юлларны карап тоту һәм ремонтлау (килешү буенча түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);

- территорияне төзекләндерү һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);

- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлау җиһазларын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);

- Ятмас Дусай авылында су башнясын карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документация өчен түләү);

-күпер ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

-Ятмас Дусай авылында зиратны карап тоту һәм ремонтлау (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект-смета документациясен эшләү;

- Ятмас Дусай авылында юлларны кардан чистарту (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

-чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

-граниттан язулы мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру).”

« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 195 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 101 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» дип гражданнар җыенында катнашучы 101 кеше тавыш бирде;
«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Ятмас Дусай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән,укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2023 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүне расларга карар иттек:

- Ятмас Дусай авылында вак таш җәеп, юлларны карап тоту һәм ремонтлау (килешү буенча түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);

- территорияне төзекләндерү һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);

- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлау җиһазларын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);

- Ятмас Дусай авылында су башнясын карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документация өчен түләү);

-күпер ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

-Ятмас Дусай авылында зиратны карап тоту һәм ремонтлау (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект-смета документациясен эшләү;

- Ятмас Дусай авылында юлларны кардан чистарту (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

-чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

-гранитан язулы мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру).”

Карар кабул ителгән дип расларга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас- Дусай
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина